ЧАРШӘМБЕ
3
МАРТ
1943 ел.
№ 51 (6773)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

СССР Совнаркомында һәм ВКП(б) Үзәк Комитетында

МТС ЛАРДАГЫ ТРАКТОРЛАРНЫ, КОМБАЙННАРНЫ ҺӘМ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ МАШИНАЛАРЫН 1943 нче ЕЛГЫ КЫР ЭШЛӘРЕНӘ ӘЗЕРЛӘҮ ТУРЫНДА

СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты 1943 нче елны барлык авыл хуҗалыгы культураларының уңышын күтәрүне төп бурыч дип саныйлар, ә бу, шактый гына дәрәҗәдә, тракторларның, комбайннарның һәм авыл хуҗалыгы машиналарының колхоз кырларында эшләүгә ничек әзерләнгән булуына һәм алардан ничек файдалануга бәйләнгән.

СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты СССР Наркомземын, өлкә башкарма комитетларын, край башкарма комитетларын, республикаларның халык комиссарлары советларын, партия өлкә комитетларын, край комитетларын һәм союзный республикалар компартияләре үзәк комитетларын, МТС ларның директорларын һәм политбүлек начальникларын үзләренең игътибарларын тракторларга, комбайннарга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына вакытында һәм югары сыйфатлы ремонт ясауга, тракторчылар, комбайнчылар, механиклар, трактор бригадалары бригадирлары сайлап алуга һәм әзерләүгә, МТС ларга барлык ягулык төрләрен туплауга, республикаларда, крайларда һәм өлкәләрдә урнашкан промышленность предприятиеләре ярдәме белән яңа запас частьлар җитештерүгә һәм искеләренә ремонт ясауга тупларга мәҗбүр иттеләр.

ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карар бирәләр:

I. ТРАКТОРЛАРГА, КОМБАЙННАРГА ҺӘМ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ МАШИНАЛАРЫНА РЕМОНТ ЯСАУ ТУРЫНДА

1. Тракторларны һәм авыл хуҗалыгы машиналарын язгы кыр эшләренә тулысынча һәм вакытында әзерләү өчен өлкә башкарма комитетлары, край башкарма комитетлары, республикаларның совнаркомнары председательләре, партия өлкә комитетларының, край комитетларының һәм союзный республикалар компартияләренең үзәк комитетларының беренче секретарьлары үзләре җаваплы икәнлеге турында кисәтеп куярга.

2. Өлкә башкарма комитетларын, край башкарма комитетларын, республикаларның совнаркомнарын, партиянең өлкә комитетларын, край комитетларын, союзный республикалар компартияләренең үзәк комитетларын, 1943 нче елның 10 нчы мартыннан соңга калмыйча, хәрби заказларны үтәүгә кимчелек китермичә, өлкә, край, республика территориясендәге промышленность предприятиеләре эшчеләреннән, һәрбер бригадада 7—10 кеше исәбеннән, квалификацияле слесарьлар, токарьлар, тимерчеләр, электросварщиклар составында 10 ар—20 шәр ремонт бригадалары төзәргә һәм аларны, бригадир (инженер яки техник) җитәкчелегендә, ремонтны үткәрүдә булышлык итү өчен, ремонт эшендә артта калучы МТС ларга һәм МТМ нарга җибәрергә мәҗбүр итәргә.

3. СССР Наркомземын, өлкә башкарма комитетларын, край башкарма комитетларын, республикаларның совнаркомнарын, партиянең өлкә комитетларын, край комитетларын, союзный республикалар компартияләренең үзәк комитетларын, МТС директорларын һәм политбүлек начальникларын беренче чиратта газогенераторлы тракторларга ремонт ясауны тәэмин итәргә мәҗбүр итәргә. Бу тракторларны кыр эшләренә әзерләү 1943 нче елның 1 нче апреленнән дә соңга калмыйча тәмам булырга тиеш. Газогенераторлы тракторларга ремонт үткәрүгә контроль ясап торуны СССР Җир Эшләре Халык Комиссары урынбасары иптәш Васинга йөкләргә.

4. Өлкә башкарма комитетларын, край башкарма комитетларын, республикаларның совнаркомнарын, партиянең өлкә комитетларын, край комитетларын, союзный республикалар компартияләренең үзәк комитетларын түбәндәгеләргә мәҗбүр итәргә:

а) 1943 нче елның 15 нче мартына кадәр, МТС директоры, политбүлек начальнигы, комбайннар буенча механик һәм шул комбайнда эшләүче комбайнчы составында төзелгән комиссия тарафыннан, һәрбер комбайнның ничек саклануына, аның техник торышына һәм ремонт кирәкме-түгелме икәнлегенә тикшерү үткәрергә;

б) комбайнчыларның тракторларга ремонт ясау эшендә булмаганнарын комбайннарга ремонт ясауда файдаланып, тракторларга ремонт ясау белән бергәттән комбайннарга ремонт ясауны оештырырга.

5. Өлкә башкарма комитетларының, край башкарма комитетларының председательләрен, республикаларның совнаркомнарын, партия өлкә комитетларының, край комитетларының һәм союзный республикалар компартияләре үзәк комитетларының беренче секретарьларын, 1943 нче елның 10 нчы мартыннан башлап 20 нче маена кадәр, тракторларга, комбайннарга, авыл хуҗалыгы машиналарына ремонтның барышы турында һәм өлкәдә, крайда, республикада булган предприятиеләрдә запас частьлар җитештерү һәм иске частьларны яңарту планын үтәүнең барышы турында СССР Совнаркомына һәм ВКП(б) Үзәк Комитетына 10 көн саен телеграф буенча хәбәр итеп торырга мәҗбүр итәргә.

6. Өлкә башкарма комитетларын, край башкарма комитетларын, республикаларның совнаркомнарын, партиянең өлкә комитетларын, край комитетларын, союзный республикалар компартияләре үзәк комитетларын түбәндәгеләргә мәҗбүр итәргә:

а) кыр эшләренә әзерлектә артта калучы һәрбер МТС ның һәм МТМ ның эшен 15 нче мартка кадәр тикшереп чыгарга һәм аларга булышлык күрсәтү, аларның эшен яхшырту буенча кирәкле чараларны күрергә;

(Ахыры 2 нче биттә).

Рәсемдә: Н-че заводның цех начальнигы иптәш К. Н. Ополлонов эшчеләргә Верховный Баш Командующий иптәш Сталинның Кызыл Армиянең 25 еллыгына чыгарган приказын укый.

С. Парфенов фотосы.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

2 нче МАРТТАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

2 нче мартка каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак Н-че часть сугышчылары зур әһәмияте булган бер биеклеккә ныгып урнашкан немецларга атака ясадылар. Штык сугышы нәтиҗәсендә безнең подразделениеләр бу биеклекне алдылар һәм 3 орудие, 4 пулемет, 146 винтовка һәм автоматлар кулга төшерделәр. Сугыш кырында дошманның 180 үле гәүдәсе калды.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак безнең бер разведка отряды төнлә белән дошман урнашкан урынга барып чыкты һәм 2 зур сугыш припаслары складын шартлатты. Бу операция вакытында 70 гитлерчы юк ителде. Икенче бер участокта Н-че часть сугышчылары дошманның атакасын кире кайтардылар һәм бер ротага якын немец пехотасын кырдылар.

* * *

Харьковтан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че берләшмә частьлары халык яши торган берничә пунктны алдылар һәм 300 дән артык гитлерчыны юк иттеләр. 9 орудие, 15 пулемет, күп снарядлар һәм патроннар кулга төшерелде. Икенче бер участокта бер группа совет автоматчиклары халык яши торган бер пунктка ныгып урнашкан дошманның тылына чыктылар һәм аңа кинәт атака ясадылар. Немецлар, 4 орудиеләрен, күп винтовкаларын һәм бер сугыш припаслары складын калдырып, чигенделәр.

Һава сугышында безнең очучылар немецларның 7 самолетын бәреп төшерделәр.

* * *

Курскидан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Н-че часть сугышчылары, каты сугыш нәтиҗәсендә, немецларның 10 танкысын зарарладылар һәм яндырдылар, 3 орудие һәм башка трофейлар кулга төшерделәр. Пленныйлар алынды. Безнең артиллерия уты белән дошманның 2 миномет батареясы юк ителде.

* * *

Кубаньда безнең очучылар һава сугышларында немецларның 11 самолетын бәреп төшерделәр. Совет самолетлары барысы да үз базаларына кайттылар.

* * *

Ленинград өлкәсендә хәрәкәт итүче бер отрядның бер группа партизаннары төнлә белән бер тимер юл разъездына һөҗүм ясаган. Совет патриотлары немец сакчыларны үтереп, стрелкаларны һәм тимер юлны шартлатканнар. Хәрби заданиедән кайткан чакта партизаннар бер тимер юл күперен шартлатканнар. Бу участокта поездлар хәрәкәте тукталган.

* * *

Кубаньда румыннарның 10 нчы пехота дивизиясе лейтенанты Николае Стан плен алынды. Ул болай диде: «Соңгы көннәрдә без руслар авиациясеннән һәм артиллерия һөҗүмнәреннән гаять зур югалтуларга дучар ителдек. Немецлар контратакага барырга приказ алгач, немец капитаны мине үз янына чакырып алды да, миңа үземнең подразделениемне аның карамагына бирергә приказ бирде. Мин моңа каршы килдем һәм, миңа оборонада булырга, һөҗүм ясамаска приказ бирелгән, дидем. Шул вакытта үләрлек хәлгә җитеп курыкнган бер немец унтер-офицеры безнең якга йөгереп килде дә: «Руслар һөҗүм итәләр», диде. Бу һәркем өчен бөтенләй көтелмәгән хәл булды. Күз ачып-йомганчы бер немец та калмады, барысы да качып беттеләр. Румыннар белән немецлар арасында мөнәсәбәтләр көннән-көн кискенләшә. Эш еш кына кара-каршы мыскыллауларга кадәр барып җитә һәм болар, гадәттә, сугышу белән бетәләр».

* * *

Түбәндә Курск өлкәсенең Рогатое поселогында немец-фашист кабахәтләр эшләгән ерткычлыклар турындагы акт игълан ителә: «Немец басып алучылар безнең поселокны 1941 нче елның октябрендә оккупацияләделәр. Шул вакыттан бирле без каторга яки төрмәдә яшәгән кебек булдык. Гитлерчылар крестьяннарны көне-төне эшләргә мәҗбүр иттеләр һәм колхозчыларга, колларга караган кебек карадылар. Ләгънәт төшкән басып алучылар, икешәр-өчәр кешене повозкаларга җигеп, авыр әйберләр ташырга мәҗбүр иттеләр. Хәлдән таеп егылган кешеләрне камчылар белән кыйнадылар. Без күргән хурлыкны, кимсетелүне һәм мыскыллануны безнең бабаларыбыз хәтта крепостнойлык хокукы заманнарында да күрмәгәннәр. Фашист ерткычлар күп колхозчыларны үтергәнче кыйнадылар һәм поселок халкын инәсеннән җебенә кадәр таладылар». Актка поселок кешеләреннән Клавдия Можарова, Анастасия Кононова, Мария Кононова һәм башкалар кул куйды.

Англия бомбардировщикларының Берлинга һөҗүме

ЛОНДОН, 2 март. (ТАСС). Англиянең авиация министрлыгының белдерүендә әйтелүенчә, 2 нче мартка каршы төндә «Ланкастер», «Галифакс» һәм «Стирлинг» самолетлары Берлинны көчле рәвештә бомбага тотканнар. Һава аяз булган, һәм, авиация министрлыгына алынган мәгълүматларга караганда, бомбага тоту уңышлы үткән. Шулай ук көнбатыш Германиядәге объектлар да бомбага тотылган. Истребитель авиациясе самолетлары Франция өстендә операцияләр үткәргәннәр.

Англиянең 19 бомбардировщигы үз базаларына кайтмаган.

ЛОНДОН, 2 март. (ТАСС). Рәсми рәвештә хәбәр ителүенчә, узган төндә Берлинга ясалган һөҗүм, моңа кадәр Германиянең башкаласына ясалган һөҗүмнәрнең барысыннан да иң көчлесе булган. Һөҗүм 30 минут дәвам иткән. Азактан очкан очучыларның сөйләүләренә караганда, алар үзләре барып җитәргә тиешле урынга җиткәнче 20 минут алдан ук Берлинда янгыннар күргәннәр. Алар яңадан әйләнеп кайтканда, инде Берлин һәм Ганновер өстеннән очканда, көчле янгыннар күргәннәр. Һөҗүмнең азагына таба шәһәрнең зур районнары күе төтен белән капланган булган. Берлинга һәркайсы 4 тоннага якын һәм 2 тоннага якын авырлыктагы бомбалар ташланган.

СССР Совнаркомында һәм ВКП(б) Үзәк Комитетында

МТС лардагы тракторларны, комбайннарны һәм авыл хужалыгы машиналарын 1943 нче елгы кыр эшләренә әзерләү турында

(Ахыры. Башы 1 нче биттә).

б) МТС ларның, МТМ нарның язгы кыр эшләренә вакытында әзерләнүләрен тәэмин итү, тракторларга, комбайннарга, авыл хужалыгы машиналарына ремонтның барышына системалы рәвештә контроль ясап һәм күзәтеп тору өчен кыр эшләре башланганчыга кадәр партия өлкә комитетларының, край комитетларының, союзный республикалар компартияләре үзәк комитетларының, шулай ук өлкә башкарма комитетларының, край башкарма комитетларының, республикалар совнаркомнарының членнарын һәм өлкәдәге, крайдагы, республикадагы башка җитәкче работникларны мәгълүм МТС ларга һәм МТМ нарга билгеләп һәм беркетеп куярга;

в) барлык МТС ларда тракторларга, комбайннарга, авыл хужалыгы машиналарына ремонт ясауның сыйфатын тикшерүне үткәрергә һәм һәрбер МТС та ремонтның вакытында һәм югары сыйфатлы итеп үткәрелүен тәэмин итү өчен кичекмәстән чаралар күрергә;

г) язгы кыр эшләренә кимендә 15 көн калганда һәрбер МТС ның язгы чәчүне үткәрүгә әзерлеген, тракторларның әзерлеген, кадрлар белән тәэмин ителгәнлекне, трактор бригадаларының участокларга беркетелгәнлеген, ягулык, майлау материаллары белән, заправка инвентаре, инструментлар һәм башкалар белән тәэмин ителгәнлекне тикшерергә һәм МТС ларның язгы чәчүгә әзерлекләрен тикшерүнең нәтиҗәләре турында СССР Совнаркомына һәм ВКП(б) Үзәк Комитетына отчетлар бирергә.

II ТРАКТОР БРИГАДИРЛАРЫ ҺӘМ ТРАКТОРЧЫЛАРНЫҢ ХЕЗМӘТЕНӘ ТҮЛӘҮ ТУРЫНДА

7. Трактор бригадаларының эшендә иясезлекне бетерү һәм аларның иген уңышын арттыру белән кызыксынуларын көчәйтү теләге белән МТС директорларын, кагыйдә буларак, трактор бригадаларын кимендә бер елга, авыл хужалыгы эшләрен үткәрү өчен, бер яки берничә янәшә колхозларның кырчылык бригадаларының мәгълүм җир участокларына беркетергә мәҗбүр итәргә. Язгы кыр эшләре башлануга кимендә ике атна калганда, трактор эшләренең төрен, күләмен һәм аларны үтәү срокларын күрсәтеп, һәрбер трактор бригадасы өчен задание билгеләргә.

8. МТС директорларын һәм политбүлек начальникларын, язгы кыр эшләре башлануга 20 көн калганда, трактор бригадаларын комплектлаштыруга һәм аларны яңа тракторчылар белән тулыландырырга мәҗбүр итәргә. Һәрбер тракторчы, кыр эшләре башланудан кимендә ике атна элек, үзенең тракторларын нагрузка белән тикшерә һәм сынап карый алырлык булсын.

9. СССР Наркомземын, 10 көн срок эчендә, бер тракторда озак вакытлар яхшы эшләгән өчен һәм аны төзек хәлдә саклаган өчен тракторчыларны күбрәк кызыксындыру турында положение проекты эшләргә һәм аны СССР Совнаркомына кертергә мәҗбүр итәргә.

10. Барлык тагылма авыл хужалыгы машиналары һәм трактор инвентаре ел башында МТС механигы тарафыннан, акт буенча, трактор бригадасы бригадирына тапшырыла дип билгеләргә. Машиналарның һәм инвентарьның саклануы өчен, аларның техник торышы өчен трактор бригадасының бригадиры трактор өчен җаваплы булган кебек җаваплы була. Авыл хужалыгы машиналарын һәм трактор инвентарен бер бригададан икенче бригадага бары тик МТС механигының яки МТС участок агрономының язма боерыгы буенча гына бирергә мөмкин.

11. Тракторларның техник торышы һәм алардан файдалану өчен җаваплылыкны арттыру теләге белән МТС та өлкән һәм алмаш тракторчы хезмәте кертергә. Өлкән тракторчыны, аеруча тәҗрибәле тракторчылар арасыннан, МТС директоры билгели, алмаш тракторчы һәм прицепщиклар аңа буйсыналар.

Өлкән тракторчы, авыл хужалыгы эшләре башланыр алдыннан, трактор бригадасы бригадиры белән бергәләп, тракторны һәм тагылма машиналарны һәм эш коралларын МТС ның өлкән механигыннан яки директорыннан акт буенча кабул итеп ала дип билгеләргә.

Авыл хужалыгы эшләре беткәннән соң өлкән тракторчы тракторны һәм тагылма машиналарны һәм эш коралларын кышка саклау өчен әзерләргә, урнаштырырга һәм, трактор бригадасы бригадиры белән бергәләп, акт буенча, СССР Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының 1942 нче ел 29 нчы ноябрьда чыгарган 1912 нче номерлы карарында күрсәтелгән тәртиптә, МТС ның өлкән механигына тапшырырга тиеш.

Өлкән тракторчы түбәндәгеләрне эшләргә тиеш:

а) һәрбер смена башланыр алдыннан тракторны һәм тагылма машиналарны һәм эш коралларын үзе карап чыгарга; аларның төп механизмнарын тикшерергә һәм кирәк булса рәтләргә;

б) тракторларга һәм тагылма машиналарга һәм эш коралларына смена саен һәм әледән-әле техник уход кагыйдәләренең үтәлүен тәэмин итәргә;

в) ягулыкны һәм майларны билгеләнгән нормадан артык тотуга юл куймаска, шулай ук файдаланылган майны җыюны һәм МТС ка тапшыруны тәэмин итәргә;

г) үзенең тракторда эшләү тәҗрибәсен алмаш тракторчы белән уртаклашырга. Өлкән тракторчы үз тракторы эшләгән эшләрнең сыйфаты өчен җавап бирә һәм бу эшләрне колхозга тапшыруда катнаша.

12. Эшне яхшырту, тракторларны, тагылма машиналарны һәм эш коралларын саклау белән өлкән тракторчының һәм аның алмашчысының кызыксынуын арттыру өчен түбәндәге тәртипне билгеләргә:

а) өлкән тракторчыга, әгәр дә ул һәм аның алмашчысы үзенә беркетелгән тракторда ике сменалык эш нормасы үтәсәләр, өстәмә рәвештә берәр хезмәт көне языла;

б) өлкән тракторчыга һәм аның алмашчысына, әгәр дә алар сезонга билгеләнгән нормаларны үтәсәләр һәм кыр эшләре беткәннән соң тракторны, тагылма машиналарны һәм эш коралларын МТС ка яхшы хәлдә тапшырсалар, Машина-трактор станциясе аларның һәрберсенең гарантияле минимум буенча МТС тан акчалата ала торган еллык хезмәт хакы күләмендә премия түли;

в) тракторларның һәм машиналарның техник хәле, тракторны, тагылма машиналарны һәм эш коралларын тапшыруны трактор бригадасы бригадиры һәм тракторчы катнашы белән, директор, политбүлек начальнигы һәм МТС ның өлкән механигы составында төзелгән комиссия тарафыннан тикшерелә.

СССР Наркомфинын СССР Наркомземының 1943 нче елгы финанс планында МТС ларның өлкән тракторчыларына һәм аларның алмашчыларына югарыда әйтелгән премияләрне түләү өчен кирәкле суммаларны күздә тотарга мәҗбүр итәргә.

13. Тракторчыларны материаль яктан кызыксындыруны арттыру, язгы кыр эшләре срокларын тизләтү һәм тракторлардан яхшырак файдалану максаты белән 1943 нче елга тракторчыларны кызыксындыру буенча түбәндәге чараларны билгеләргә:

а) «Универсал» тракторында эшләүче һәм беренче календарь 15 көндә үз сменаларында, йомшак сөрүгә күчереп исәпләгәндә, сөрү, тырмалау, культивацияләү һәм чәчү буенча кимендә 35 гектар эшләгән МТС тракторчылары 30 хезмәт көне күләмендә премия алалар. Шуның өстенә МТС тракторчылары шул ук вакыт эчендә 35 гектардан тыш эшләнгән һәрбер гектар өчен берәр өстәмә хезмәт көне алалар;

б) СХТЗ тракторында эшләүче һәм беренче календарь 15 көндә үз сменаларында, йомшак сөрүгә күчереп исәпләгәндә, сөрү, тырмалау, культивацияләү һәм чәчү буенча кимендә 45 гектар эшләгән МТС тракторчылары 35 хезмәт көне күләмендә премия алалар. Шуның өстенә МТС тракторчылары шул ук вакыт эчендә 45 гектардан тыш эшләнгән һәрбер гектар өчен берәр өстәмә хезмәт көне алалар;

в) СХТЗ-НАТИ тракторында эшләүче һәм беренче календарь 15 көндә үз сменаларында, йомшак сөрүгә күчереп исәпләгәндә, сөрү, тырмалау, культивацияләү һәм чәчү буенча кимендә 90 гектар эшләгән МТС тракторчылары 40 хезмәт көне күләмендә премия алалар. Шуның өстенә МТС тракторчылары шул ук вакыт эчендә 90 гектардан тыш эшләнгән һәрбер гектар өчен 0,6 өстәмә хезмәт көне алалар;

г) ЧТЗ тракторында эшләүче һәм беренче календарь 15 көн эчендә үз сменасында, йомшак сөрүгә күчереп исәпләгәндә, сөрү, тырмалау, культивацияләү һәм чәчү буенча кимендә 120 гектар эшләгән МТС тракторчылары 45 хезмәт көне күләмендә премия алалар. Шуның өстенә МТС тракторчылары шул ук вакыт эчендә 120 гектардан тыш эшләнгән һәрбер гектар өчен 0,5 өстәмә хезмәт көне алалар;

д) газогенераторлы СХТЗ-НАТИ тракторында эшләүче һәм беренче календарь 15 көндә үз сменасында, йомшак сөрүгә күчереп исәпләгәндә, сөрү, тырмалау, культивацияләү һәм чәчү буенча кимендә 65 гектар эшләгән МТС тракторчылары 40 хезмәт көне күләмендә премия алалар. Шуның өстенә МТС тракторчылары шул ук вакыт эчендә 65 гектардан тыш эшләнгән һәрбер гектар өчен 0,8 өстәмә хезмәт көне алалар;

е) газогенераторлы ЧТЗ тракторында эшләүче һәм беренче календарь 15 көндә үз сменасында, йомшак сөрүгә көчереп исәпләгәндә, сөрү, тырмалау, культивацияләү һәм чәчү буенча кимендә 95 гектар эшләгән МТС тракторчылары 45 хезмәт көне күләмендә премия алалар. Шуның өстенә МТС тракторчылары шул ук вакыт эчендә 95 гектардан тыш эшләнгән һәрбер гектар өчен 0,6 өстәмә хезмәт көне алалар.

14. ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомының «Машина-трактор станцияләренең эше турында» 1939 нчы ел 13 нче январь карарында әйтелгәнчә ягулык тотуны 10 процентка арттыру тәртибен 1943 нче елны язгы сөрүнең беренче алты көнендә язгы чәчү эшләренә һәм культивациягә дә җәелдерергә.

15. Колхозларга—әгәр дә МТС ның участок механигына беркетелгән бригадалар эш сыйфатын яхшы итеп, билгеләнгән трактор эшләре планын үтәсәләр, бу механикка ашлыклата 20 пот күләмендә натуралата премия бирергә киңәш итәргә. Бу күләмдәге ашлыкны, үз басуларында үтәлгән трактор эшләренә пропорциональ рәвештә, колхозлар аерып куярга тиешләр.

16. Тракторга тагыла торган машиналарда һәм эш коралларында эшләү өчен, трактор бригадаларына ягулык һәм су китерү өчен колхоз, кыр эшләре башланудан бер ай элек, МТС советында расланган планга туры китереп, тәмам әзерлекле колхозчыларны билгеләп куярга тиеш.

Тракторларга тагыла торган машиналарда һәм эш коралларында, ягулык һәм су китерүдә эшләү өчен билгеләнгән колхозчыларны МТС директоры бөтен авыл хужалыгы елына трактор бригадаларына билгели һәм аларны колхоз, МТС директорының ризалыгы булмаганда, бөтен ел буена башка эшләргә чыгарып ала алмый.

Прицепщикларның хезмәтенә аларның эшләгән хезмәт көннәре буенча түләү, алар кайсы колхозларның кырларында эшләгән булсалар, шул колхозлар тарафыннан, шул колхозда билгеләнгән бәяләр буенча натуралата һәм акчалата үткәрелә дип билгеләргә.

17. Колхозларга—кырчылык трактор бригадалары эшләгән кыр эшләренең сыйфатына контроль алып бару өчен, колхозның гомуми җыелышында 1—2 тәҗрибәле колхозчыны яки колхозчы хатын-кызны билгеләргә киңәш бирергә.

Кыр эшләренең сыйфатына контроль алып бару өчен билгеләнгән колхозчылар үзләренең эшнең сыйфатын тикшерү эшләрен МТС агрономы җитәкчелегендә алып баралар дип билгеләргә.

* * *

СССР Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП (б) Үзәк Комитеты союзный республикалар компартияләренең үзәк комитетларын, партиянең край, өлкә һәм район комитетларын МТС ларның 1942 нче елгы эш йомгакларын 1943 нче елның 20 нче мартына кадәр тикшерергә һәм МТС ларның эшен яхшырту, тракторларга, комбайннарга һәм катлаулы авыл хужалыгы машиналарына ремонт ясауда һәм алардан файдалануда үткән елны булган кимчелекләрне бетерү буенча чаралар күрергә мәҗбүр иттеләр.

Бу карарны МТС ларның производство советларында, тракторчылар, комбайнчылар, МТС эшчеләре һәм хезмәткәрләре киңәшмәләрендә тикшерергә.

ТАТАРСТАННЫҢ БАРЛЫК КОЛХОЗЧЫЛАРЫНА ҺӘМ КОЛХОЗЧЫ ХАТЫН-КЫЗЛАРЫНА

АПАС РАЙОНЫ, „ЯҢА ИЛ“ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ АРТЕЛЕ КОЛХОЗЧЫЛАРЫНЫҢ ҺӘМ КОЛХОЗЧЫ ХАТЫН-КЫЗЛАРЫНЫҢ

МӨРӘҖӘГАТЕ

Кадерле иптәшләр!

Верховный Баш Командующий иптәш Сталинның приказын без үзебезнең җыелышта гаять зур рухлану белән өйрәндек. Ватаныбызның явыз дошманын—кабахәт немец оккупантларын тизрәк юк итү өчен нәрсә эшләргә кирәклеген безнең атабыз, остазыбыз һәм юлбашчыбыз ачык күрсәтте.

Сөекле полководецыбыз иптәш Сталин Кызыл Армияне һәм Советлар илен яңадан-яңа җиңүләргә алып бара. Сталинград янында, Төньяк Кавказда һәм Дон буенда немецларны тар-мар итеп, Ленинградның блокадасын өзеп; данлыклы кызыл сугышчылар һаман алга, көнбатышка таба баралар. Совет иленнән дошманны масса төсендә куу башланды.

Немец ерткычларның артка таба чигенүләре очраклы түгел. Фашистик Германия һәм аның талаучылар армиясе торган саен көчсезләнә бара. Ә безнең Кызыл Армиябез көн саен ныгый һәм немец-фашист басып алучыларга тагын да җимергечрәк ударлар ясый. Безнең бөек халкыбыз Кызыл Армиягә ярдәмне арттырганнан-арттыра бара, үзенең резервларын күбәйткәннән-күбәйтә бара. Данлыклы совет патриотлары тылда шундый итеп эшлиләр ки, Кызыл Армия танкларны, самолетларны, орудиеләрне, авыл хуҗалыгы продуктларын өзлексез рәвештә күбрәк һәм күбрәк санда алып тора.

Дошманны җиңү өчен корал коючы совет патриотлары семьясында безнең «Яңа ил» колхозы да соңгы сафларда булмаганлыкны без шатланып белдерәбез. Безнең колхозның иң яхшы уллары фронтта гитлерчы бандитларга каршы геройларча сугышалар. Без, сугышчан хезмәтләре өчен Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнгән авылдашыбыз Мөхәммәтгалиев белән, Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгән колхозчы иптәш Вәлиев белән мактанабыз.

Безнең колхозчылар үз кырларында армый-талмый эшлиләр. Эшче көчләренең һәм тарту көчләренең кимүенә дә карамастан, колхоз барлык эшләрне срогыннан элек үти. Без 1942 нче ел уңышын тиз һәм югалтусыз җыеп алдык, авыл хуҗалыгы продуктларын мәҗбүри тапшыру буенча дәүләт йөкләмәләрен тулысынча үтәдек. Безнең колхоз сугыш башланганнан бирле дәүләткә барлыгы 35.520 пот ашлык, 562 пот ит, 36.122 литр сөт, 10.114 дана йомырка, 13 пот 28 кадак йон, 80 килограмм брынза, 175 данә тире тапшырды. Шефлык итә торган госпитальгә күп санда ит, яшелчә җибәрелде. Оборона заводы эшчеләренә 3 үгез, 30 пот бодай, 18 пот борчак бирелде.

Безнең колхозчылар 131.000 сумлык хәрби заем облигацияләре, 68.720 сумлык акчалата-әйберләтә уйнала торган лотерея билетлары алдылар, героик партизаннарга бүләк өчен 5.681 сум җыйдылар. Танклар колоннасы һәм самолетлар эскадрильялары төзү өчен 316.500 сум акча җыелды. Шул исәптән колхоз председателе иптәш Сәйхунов—46.250 сум, трактор отряды бригадиры иптәш Гыйбадуллин—25.000 сум керттеләр. Фронтка бик күп җылы киемнәр, шулай ук ит, май, йомырка һ. б. әйберләрдән бүләкләр җибәрелде.

Кадерле иптәшләр!

Безнең даһи полководецыбыз иптәш Сталин үзенең приказында дошманны тәмам җиңүнең юлларын билгеләде. Ул безнең барыбызны да тыныч күңелле булмаска, гамьсез булмаска чакыра һәм җиңү белән масаймаска һәм мактанмаска приказ бирә. Дошман җиңелүләргә дучар ителә, ләкин әле ул җимерелмәгән. Алда мәкерле, рәхимсез һәм әлегә көчле дошманга каршы кискен көрәш тора. Бу көрәш вакыт, корбаннар, безнең барлык көчләребезне җигүне таләп итә, безнең барлык резервларыбызны туплауны таләп итә. Без сөекле Иосиф Виссарионовичның бу даһи күрсәтмәсен тулысынча һәм бөтенләе белән аңлыйбыз, моңа кадәр фронт өчен без эшләгәннәр әле бөтенләй җитәрлек түгел дип саныйбыз. Тагын да күбрәк һәм яхшырак эшләргә кирәк.

Бездә һәм Татарстандагы башка барлык колхозларда да әле файдаланылмаган резервлар бик күп. 1943 нче елда Кызыл Армиягә һәм илебезгә ашлыкны һәм башка продуктларны узган елдагыга караганда күп тапкырлар артыграк бирү—безнең беренче бурычыбыз һәм изге эшебез. Без, колхозның 1943 нче ел уңышыннан планнан тыш фронтка күпме ашлык бирә алачагын исәпләдек һәм быел һәрбер гектардан кимендә 100 пот уңыш алырга һәм мәҗбүри йөкләмәләрдән тыш Кызыл Армия фондына 8.000 пот ашлык бирергә карар иттек. Моның нигезләре бар: без уҗым культураларын планнан тыш 42 гектар чәчтек, яз көне планнан тыш 100 гектар сабан культуралары чәчәбез, оборона фондына махсус рәвештә 5 гектар чәчәбез, шуның өстенә колхозчылар үз запасларындагы орлыклар белән оборона фондына берничә гектар чәчәчәкләр.

Хәзер үзебезнең барлык көчебезне һәм кайгыртучанлыгыбызны язгы кыр эшләренә үрнәк төстә әзерләнүгә бирәбез. Без орлыкларны җитәрлек кадәр чистартып салып куйдык, аларның тишелешләрен тикшерәбез, кышкы агротехника чаралары планын арттырып үтәү өчен ныклы көрәш алып барабыз. Кырга инде 2.700 йөк тирес чыгарылды, 90 пот көл җыелды, 104 пот кош тизәге җыелды, 300 гектар мәйданда кар тотылды. Сабаннарга, чәчү машиналарына, тырмаларга, сбруйларга ремонт ясауны төгәлләп киләбез. Колхозда регуляр рәвештә агротехника түгәрәге эшли. Атларны тәрбияләү кискен төстә яхшырды, кыр эшләрендә файдалану өчен үгезләр өйрәтәбез. Куксагыз, махорка буенча звенолар; шулай ук яшелчә бригадасы язга ныклап әзерләнәләр. Фермаларда эш кайный. Терлекчеләр терлекләр санын үстерү планын үтәү һәм арттырып үтәү өчен көрәшәләр.

Безнең колхоз агымдагы елның беренче өч кварталы өчен ит тапшыру планын үтәде инде.

Бригадалар, звенолар һәм аерым колхозчылар арасында; язга яхшы әзерләнү һәм язгы чәчүне яхшы итеп үткәрү буенча актив ярыш алып барыла. Без үзебез белән күрше булган «Дәвеш» колхозын ярышка чакырдык. Язгы чәчүне 7—8 көндә үткәрергә, 100 потлы уңыш алу өчен чәчүлекләрне җентекләп тәрбияләргә сүз бирәбез.

ИПТӘШ СТАЛИННЫҢ ПРИКАЗЫНА БЕЗ ШУЛАЙ ҖАВАП БИРӘБЕЗ.

Кадерле иптәшләр, Татарстанның колхозчылары һәм колхозчы хатын-кызлары, без сезне барыгызны да, бер кешедәй булып, югары хәрби уңыш өчен, язгы чәчүгә үрнәк төстә әзерләнү һәм үткәрү өчен көрәшкә чакырабыз.

ЯРЫШКА ЧЫГЫГЫЗ, ИПТӘШЛӘР! Һәрбер колхозда кичекмәстән орлыкларның тулысынча салынган һәм әзерләнгән булуы өчен көрәшегез. Сабаннарны, тырмаларны культиваторларны, чәчкечләрне, арбаларны, сбруйларны һәм язгы чәчүгә кирәк булган башка инвентарьларны тизрәк һәм яхшырак итеп ремонтлау өчен үзегезнең тимерчеләрегезне, балта осталарыгызны, камытчыларыгызны мобилизацияләгез. Колхозларның ат караучылары атларны язгы кыр эшләренә яхшы итеп әзерләү өчен тырышсыннар. Атларның торышына күзәтчелекне көчәйтегез, аларны чиста тотыгыз. Аларны вакытында ашатыгыз һәм эчертегез.

КОЛХОЗ АГРОТЕХНИКЛАРЫ! Югары уңышның язмышы күп хәлләрдә сезгә бәйләнгән. Кышкы агротехника чаралары планының үтәлүе өчен көрәшегез, кырга тирес чыгару, көл һәм башка җирле ашламалар җыюны көчәйтегез; чәчү вакытында агротехника чараларының төгәл үтәлүен күзәтегез.

Чәчүгә санаулы көннәр генә калды. Һәрбер сәгатьне, һәрбер минутны чәчүгә әзерлектә булган кимчелекләрне бетерү өчен файдаланыйк.

КОЛХОЗЛАРНЫҢ ПРЕДСЕДАТЕЛЬЛӘРЕ, БРИГАДИРЛАРЫ, АГИТАТОРЛАР! Хезмәт дисциплинасын ныгыту өчен; хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү өчен көрәшегез. Чәчүгә яхшы әзерлек язгы чәчүнең уңышлы үтүен хәл иткәнлекне һәм, димәк; алдагы елның иген уңышының язмышын хәл иткәнлекне һәрвакыт истә тотыйк.

ИПТӘШЛӘР, ТАТАРСТАН КОЛХОЗЧЫЛАРЫ! Иптәш Сталинның приказына бердәм стахановча эш белән, язгы чәчүгә үрнәк рәвештә әзерләнеп һәм үткәреп җавап бирик. Быелгы елда фронтка һәм илгә ашлыкны, итне; сөтне, яшелчәләрне күбрәк бирик. Ерткыч һәм кабахәт дошманны ләгънәт төшкән немецларны тәмам тар-мар итүдә туганыбыз Кызыл Армиягә булышу өчен бөтенесен дә эшлик.

Яшәсен сөекле ватаныбыз!

Яшәсен героик Кызыл Армия!

Яшәсен совет халкының барлык җиңүләрен рухландыручы һәм оештыручы, Кызыл Армиянең Верховный Баш Командующие бөек Сталин!

Немец оккупантларына үлем!

Колхозның гомуми җыелышының тапшыруы буенча: Апас районы, «Яңа ил» колхозы председателе **Г. СӘЙХУНОВ.** Дәүләки авыл советы председателе **Х. САФИН** Авыл советы секретаре **Х. БАҺАВЕТДИНОВА.** Агротехник **Х. БИКБОВ.** Колхоз счетоводы **К. ХИСАМОВ.** Авыл китепханәсе мөдире **Ш. ҖАМАЛИЕВ.** Мәктәп мөдире **Ш. КАМАЛОВА.** Укытучы **Н. АЛАЕВА.** Бригадирлар. **Р. САДРИЕВА** һәм **Ф. САБИТОВА.** Күксагыз буенча звено башлыгы **А. ШӘМСИЕВА.** Колхозчылар: **Н. КАДИРОВА. Ф. ГАЛИЕВА, М. ХӨСӘЕНОВА, К. МӨНАСИПОВА, Н. ҖАМАЛИЕВА, И. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН, Н. ГАЙНУЛЛИН.** Терлекчеләр: **Х. ГАЛИЕВ, Х. ХӘМИДУЛЛИНА; М. БУЛАТОВА.**

Рәсемдә: Н-че заводның стахановчысы иптәш М. Таҗиева. Ул күптән түгел СССР җиңел премышленносте наркоматының почет значегы белән бүләкләнде.

С. Парфенов фотосы.

ТИМЕР ЮЛЧЫЛАР ЯРЫШЫ

Алдынгылык өчен көрәштә

Юдинодагы ягулык склады байтак вакытлар буе бөтен паровоз паркының эшенә тоткарлык ясап килә иде. Локомотивлар, утын алу өчен, эстакада янында чират торалар, шуның аркасында алар тәүлеккә 5—6 сәгать простой ясыйлар иде. Бу сәгатьләр хәрәкәттә үтсәләр, һәрбер паровоз 120—150 километрга артык поезд йөртә алыр иде.

Склад паровозларны 10—12 сантиметр калынлыкта ярган стандарт утын белән түгел, стандарт булмаган калын бүрәнә кисәкләре белән генә тәэмин итеп килде, һәм бу хәл шулай ук паровозларның нормаль эшләүләренә шактый комачаулык ясый иде.

Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә багышланган ярышны киң җәелдерү бу складны арттагы урыннан иң алдынгы урыннарның берсенә чыгарды. Күптән түгел аңа Казан тимер юлының күчмә Кызыл Байрагы тапшырылды.

Коллективта күп кенә булган татар эшчеләре арасында политик-масса эшләрне көчәйтү чаралары да бу уңышларга ирешүгә нык ярдәм итте. Склад политругы иптәш Янбулатов татар эшчеләре арасында ана телендә системалы рәвештә беседалар, лекцияләр үткәрә, кычкырып газеталар укый.

Коллективта җәелеп киткән социалистик ярышта иптәш Габделкәбир Шакиров бригадасы иң алдынгы булып бара. Эшнең техникасын ныклап үзләштерү, кышкы кыенлыкларны уңышлы җиңү нәтиҗәсендә, бу бригада паровозларга ягулык утынны иң кыска срокта —12—15 минут эчендә төяп өлгертә.

Ягулык утынның сыйфаты да шактый яхшырды. Утынны кисү һәм яру эшләре хәзер кызу темплар белән алып барыла. Иптәш Кашин бригадасында эш аеруча уңышлы оештырылган. Бу бригада заданиеләрне өч тапкырга арттырып үти башлады. Иптәш Коновалов бригадасы да нормаларны 200 процентка үти. Кайбер көннәрне складта 380—400 кубометр утын киселә. Бу—паровоз паркын тулысынча тәэмин итәргә җитә диярлек.

Локомотивларны күмер белән тәэмин итүче кранчылар да үз эшләрен бик нык яхшырттылар. Күмер төяүдә машиналар элек бик күп простой торалар иде. Хәзер бу простой 7 минуттан артмый.

Н. ГУСЕВ.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ӘЗЕРЛЕК УҢЫШЛЫ БАРА

Норлат районының «Игенче» колхозы узган елгы авыл хуҗалыгы эшләрен һәм шулай ук дәүләт алдындагы барлык йөкләмәләрне беренче булып үтәгән иде. Колхозчылар быелгы авыл хуҗалыгы эшләрен тагын да яхшырак үтәү, Кызыл Армиябез өчен ашлыкны, ит, сөт, май һәм башка продуктларны тагын да мулрак итеп җитештерү өчен тырышып эшлиләр.

Колхозда язгы чәчүгә әзерлек эшләре бик күпләргә үрнәк булырлык уңышлы бара. Барлык культуралар буенча да чәчүлек орлыклар әзер. Аларның сыйфаты яхшы, тишелеп чыгышлары югары.

Язгы чәчү вакытында кирәк булачак барлык машиналарга һәм шулай ук сбруйларга ремонт күптән төгәлләнгән. Капчыклар, торпыша һәм башка шундый әйберләр дә җитәрлек бар.

Кышкы агротехника чараларын үтәүгә нык әһәмият бирелә. Басуга 3.536 йөк тирес чыгарылып, план шактый арттырып үтәлгән. 22 центнер кош тизәге, 50 центнерга якын көл җыйналган. Шулай ук кар тоту планы да тулысынча үтәлгән. Атларның торышы канәгатьләнерлек.

Кызыл Армиянең XXV еллыгы уңае белән колхозчылар фронтовикларга бүләкләр җибәрделәр. Алар ашлык, ит, йомырка һәм башка шундый продуктлар тапшырдылар.

Р. ХӘСӘНОВА.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

2 нче МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

2 нче мартта безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

Баренц диңгезендә безнең корабльләр дошманның 8.000 тонна авырлыктагы бер транспортын һәм 800 тонна авырлыктагы бер сакчы кораблен батырдылар.

* * *

1 нче мартта безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында дошманның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 100 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 18 артиллерия батареясының утын бастырдылар һәм бер сугыш припаслары складын шартлаттылар.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак Н-че берләшмә частьлары һөҗүм сугышларын дәвам иттерделәр. Безнең сугышчылар, дошманның каты каршылык күрсәтүен җиңеп һәм аның контратакаларын кире кайтарып, немецлар оборонасының эчендә көрәш алып баралар. Дошманның 8 танкысы, 18 орудиесе, 24 пулеметы, 20 автомашинасы юк ителде һәм 600 гә якын гитлерчы кырып ташланды. 4 немец самолеты бәреп төшерелде.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак Н-че часть сугышчылары, дошманның контратакасын кире кайтарып, аның ике танкысын сафтан чыгардылар һәм бер ротага якын пехотасын юк иттеләр. Халык яши торган бер зур пункт районында дошманның ике пехота взводыннан торган разведка отряды тулысынча кырып бетерелде.

* * *

Харьковтан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүм сугышларын дәвам иттерделәр. Дошман резервлар китерде һәм берничә тапкыр уңышсыз контратакалар ясады. Сугыш нәтиҗәсендә бу участокта немецларның яңа гына Голландиядән килгән 167 нче пехота дивизиясе булганлыгы беленде. Н-че часть сугышчылары, гитлерчыларның каршылык күрсәтүен бастырып, алга киттеләр һәм халык яши торган бер зур пунктны алдылар. Бу пункт өчен булган сугышта дошманның 400 гә якын солдат һәм офицерлары үтерелде һәм яраланды. Немецларның 3 танкысы, 7 орудиесе һәм 6 автомашинасы юк ителде. Икенче бер участокта иптәш Улитин командалыгындагы частьлар халык яши торган бер пунктны чолгап алдылар һәм 5 көн сугышканнан соң аны кулга төшерделәр. Дошман гарнизоны юк ителде. Сугыш припаслары һәм азык тутырылган склад-лар һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Курскидан көнбатыштарак Н-че часть сугышчылары, кискен атака нәтиҗәсендә, дошманның ныгытылган позицияләрен алдылар. Безнең артиллериябез уты белән немецларның күп кенә ДЗОТ лары җимертелде, бер миномет һәм 2 артиллерия батареясының уты бастырылды.

* * *

Кубаньда безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бу пунктларның берсендә Н-че часть подразделениеләре 5 орудие, 1 әйбер склады, бер сугыш припаслары склады һәм күп төрле пехота кораллары кулга төшерделәр.

* * *

Минск өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды 1 нче февральдән 20 сенә кадәр 100 дән артык гитлерчыны кырган, 6 пулемет, 44 винтовка һәм 4 револьвер кулга төшергән. Шул ук вакыт эчендә партизаннар дошманның 7 хәрби эшелонын юлдан чыгарганнар. Немец солдатлары һәм кораллар төялгән 52 вагон җимерелгән.

Шушы көннәрдә Минск өлкәсенең «Железняк» исемле отрядының партизаннары кинәт зур тимер юл станциясенә һөҗүм иткәннәр. Станция өчен сугыш берничә сәгать дәвам иткән. Немец сакчыларының күп өлеше үтерелгән, ә калганнары качып киткән. Партизаннар, станцияне кулга төшереп, тимер юл корылмаларын шартлатканнар.

* * *

Немецларның 8 нче егерь дивизиясенең 28 нче полкының 1 нче ротасыннан плен алынган обер-ефрейтор Леопольд Бишоф болай ди: «1942 нче елны мин Барановичи шәһәрендә сакчы батальонда хезмәт иттем. Бу батальон төрмәне, концентрация лагерын һәм хәрби пленныйлар лагерын тышкы яктан саклау хезмәтен үти иде. Яз көне Барановичи төрмәсенә поляк заложниклары белән бер транспорт килде: Озакламый аларның барысын да атып үтерделәр. Май башларында бер көн эчендә генә дә 70 ксендз, 18 хатын-кыз һәм Польша армиясенең элекке офицерларыннан 11 кеше атылды. Аларны хәрби пленныйлар лагеры артында аттылар».

* * *

Горни Лапац районында өч көн дәвам иткән бик каты сугышларда Югославия партизаннары 470 итальянны кырганнар һәм итальяннарның 152 нче полкының бер танкысын, 16 автомашинасын; 8 тонна бензинын һәм бер обозын юк иткәннәр: Партизаннар ике танк, 3 орудие, 5 миномет; 13 пулемет; 100.000 патрон, 6 радиостанция һәм башка сугыш милекләре кулга төшергәннәр: Прозор районында партизаннар итальяннарның туздырылган частьларын куып баруны дәвам иттерәләр.

ПОЛЬША—СОВЕТ МӨНАСӘБӘТЛӘРЕ ТУРЫНДА ПОЛЬША ХӨКҮМӘТЕНЕҢ БЕЛДЕРҮЕ

ЛОНДОН, 25 февраль. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, бүген кич белән Польша хөкүмәте рус-поляк мөнәсәбәтләре турында түбәндәге белдерүне игълан иткән: «25 нче февральдә Польша хөкүмәте генерал Сикорский председательлегендәге утырышында Польша—Совет мөнәсәбәтләре турындагы мәсьәләне тикшерде һәм түбәндәге карарны кабул итте: «Хәзерге сугыш башланганга кадәр дә, сугыш вакытында да поляк халкының Советлар Союзына каршы немецлар белән нинди булса да хезмәттәшлек итәргә риза булмаганлыгын Польша хөкүмәте яңадан раслый. СССР белән булган ике арадагы мөнәсәбәтләрендә Польша сугышны алып баруда Советлар Союзы белән хезмәттәшлек итәргә һәм җиңүдән соң дусларча яхшы мөнәсәбәтләрне сакларга һәрвакыт әзер торганлыгын күрсәтте. Польшаны Советлар Россиясенә карата кыеклатып яки турыдан-туры дошманлык тенденцияләрендә булуда гаепли торган һәм усаллык белән чыгарылган пропаганданы Польша хөкүмәте кискен рәвештә кире кага. Польша республикасының көнчыгыш чикләрен Днепрда яки Кара диңгездә төзәргә теләүдә Польшадан шикләнү яки үзенең чикләрен тагын да көнчыгышкарак киңәйтүгә Польшага нинди булса да тенденцияләрне тагу бөтенләй мәгънәсез.

Үзенә көчләп тагылган көрәшкә берләшкән милләтләрдән беренче буларак керешкән һәм шул вакыттагы чикләрендә Польшаның вәкиле булган Польша хөкүмәте, 1941 нче елның 30 нчы июлендә Польша—Совет договоры төзелгән вакыттан бирле Польша белән Советлар Союзы арасындагы чикләр турындагы мәсьәләдә 1939 нчы елның беренче сентябренә кадәр яшәп килгән статус-кво саклана дигән позицияне үзгәрешсез рәвештә яклап килде, һәм Атлантика хартиясенә туры килә торган бу позицияне җимерү берләшкән милләтләрнең бердәмлегенә зарар китерә, дип саный. Польша хөкүмәте, барлык союзниклар арасында тыгыз хезмәттәшлек һәм ышаныч җинүнең һәм даими тынычлыкның кирәкле факторы булып тора дип исәпли һәм берләшкән милләтләрнең бердәм фронтын бозуга яки йомшартуга юнәлдерелгән барлык актларны һәм белдерүләрне гаепли».

Польша хөкүмәтенең шушы ел, 25 нче февральдәге декларациясе уңае белән ТАСС-ның белдерүе

Совет-Польша мөнәсәбәтләре турында Польша хөкүмәтенең шушы ел, 25 нче февральдә Лондонда игълан ителгән белдерүе, украин һәм белорус халыкларының үз милли дәүләтләрендә берләшкән булуларыннан торган тарихи хокукларын Польша хөкүмәтенең танырга теләмәгәнлеген күрсәтә. Украинаның һәм Белоруссиянең күптәнге җирләрен үзара бүлешкән империалистик дәүләтләрнең басып алу политикасын законлы дип исәпләүне дәвам иттерүдән булырга кирәк, украинлыларның һәм белорусларның үз милли дәүләтләре чикләрендә яңадан кушылуларыннан гыйбарәт булган һәркемгә билгеле фактны санга алмыйча, Польша хөкүмәте шулай итеп Украина һәм Белоруссия җирләрен бүлү, украин һәм белорус халыкларын ваклау политикасын дәвам иттерүне аклап чыгыш ясый.

Советларның җитәкче даирәләре, украин һәм белорус халыкларының үзләренең бер нәселдән булган туганнары белән яңадан кушылу хокукларын инкар итү империалистик тенденцияләрнең булганлыгын күрсәтә дип, Польша хөкүмәтенең Атлантика хартиясенә таянуының бер төрле дә нигезе юк, дип саныйлар. Атлантика хартиясе украин һәм белорус халыкларының милли хокукларына кул тидерергә бер кемгә дә хокук бирми, бәлки киресенчә, ул халыкларның милли хокукларын, шул исәптән украин һәм белорус халыкларының да милли хокукларын тану принципларыннан чыгып эш итә.

Хәтта Британиянең мәгълүм министры лорд Керзон да, СССР га дуслык карашларында булмавына да карамастан, Украина һәм Белоруссия җирләрен Польшаның дәгъва итә алмавын аңлады, ә Польшаның хаким даирәләре шушы вакытка кадәр бу мәсьәләне аңлаганлыкларын күрсәтергә теләмиләр.

Бу, сугыш башланганга кадәр Польша Советлар Союзына каршы Германия белән нинди булса да хезмәттәшлек итәргә риза булмады дип, Польшаның хаким даирәләренең раслаулары чынбарлыкка туры килми, чөнки Польша хөкүмәтенең һәм аның министры Бекның Гитлер Германиясе белән якынлашудан һәм фашистларны яклаудан торган политикасы, аларның Польшаны Советлар Союзына каршы куярга омтылганлыклары бөтен дөньяга мәгълүм.

Хәзерге заман сугышы нәрсәгә булса да өйрәтә икән, барыннан да элек ул славян халыклары үзара дошман булмаска тиешләр дип, бәлки немецлар тарафыннан изелү куркынычыннан котылу өчен дус яшәргә тиешләр дип өйрәтә. Польшаның хаким даирәләре Украина һәм Белоруссия җирләренә кул сузалар икән һәм шуның белән Польша халкы һәм Украина, Белоруссия халыклары арасында дошманлык салалар икән, димәк, алар бернәрсәгә дә өйрәнмәгән булалар, чөнки Польшаның хаким даирәләренең мондый политикасы, барыннан да элек, Польшаның үзен загыйфьләндерә һәм Германиянең басып алуына каршы көрәштә славян халыкларының бердәм фронтын җимерә.

Польша хөкүмәтенең белдерүе Польшаның хәзерге хаким даирәләренең бу мәсьәләдә поляк халкының чын фикерен чагылдырмаганлыкларын күрсәтә. Поляк халкының интереслары, үзләренең ватанын азат итү өчен көрәштә һәм нык, көчле Польшаны яңадан торгызуда Украинаның, Белоруссиянең туган халыклары белән, шулай ук рус халкы һәм СССР ның башка халыклары белән үзара ышанычны һәм дуслыкны һәрьяклап ныгыту эше белән һич тә өзелмәслек булып бәйләнгән.

ДАНИЯДӘ НЕМЕЦЛАРГА ҺӨҖҮМ

СТОКҺОЛЬМ, 1 март. (ТАСС). Швеция телеграф агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Кольдинг шәһәрендә (Дания) Германия армиясендә хезмәт итүче 25 немец хатын-кызы һәм хезмәткәрләре урнашкан югары мәктәп бинасында бомба шартлаган. Гаеплеләр табылмаганнар. Бу һөҗүмнән соң полиция барлык зур заводларда һәм тимер юл линияләрендә полиция постлары урнаштырган. «Саботажга каршы көрәшүче полиция корпусы» төзелгән.

СВОДКА

ТАТАРСТАН АССР МТС ЛАРЫНДА ТРАКТОРЛАРГА РЕМОНТНЫҢ БАРЫШЫ ТУРЫНДА

1943 нче елның 25 нче февраленә

(Планга карата процентларда)

МТС лар	Үтәлеш
1. Мөслим	100,0
2. Чокалы	100,0
3. Актаныш	100,0
4. Бөгелмә	100,0
5. Нөркәй	100,0
6. Алга	100,0
7. Тымытык	100,0
8. Алабуга	100,0
9. Тирсә	100,0
10. Ишеево	100,0
11. Чүпрәле	100,0
12. Дөбьяз	100;0
13. Саба	96,0
14. Яниль	88,6
15. Мөрәле	87,2
16. Дәүләкиң	87,0
17. Сарман	86,8
18. Кадряк	86,5
19. Юртыш	85,7
20. Чүрибураш	83,0
21. Октябрь	82,8
22. Т. Тамак	82,1
23. Азин	81,0
24. Зөя	81,0
25. Поповка	80,5
26. Тархан	80,3
27. Заинский	79,3
28. Чыбыклы	77,8
29. Димитров	77,1
30. Соколка	76,5
31. Норлат	76,2
32. Иске Тимошкино	75,4
33. Аксубай	75,0
34. Кузайкино	74,5
35. Чаллы	74,5
36. Акташ	74,1
37. Юдино	73,3
38. Исәнбай	73,0
39. Б. Матак	72,5
40. Кызыл йолдыз	72,2
41. Олы Карилe	72,0
42. Мәлки	72,0
43. Тәтеш	70,8
44. Калинин	70,0
45. Кукмара	67,9
46. Балтач	67,3
47. Әлмәт	66,7
48. Кичү	66,7
49. Кызыл Чапчак	66;1
50. Яңа Чишмә	64,7
51. Бондюг	64,4
52. Шөгер	64,2
53. Тельман	63,9
54. Каргалы	63,3
55. Баулы	63,0
56. Беренче Май	62,7
57. Рождественский	62,5
58. Чалпы	62,2
59. Мактауш	62,1
60. Әтнә	62,0
61. Куйбышев	61,4
62. Теләче	61,2
63 Тәкәнеш	60,4
64. Ютазы	60,0
65. Зирекле	59,6
66. Әлши	59,5
67. Кәкре елга	59,0
68. Чистай	58,8
69. Мөслим (Чистай)	58,8
70. Алексеевский	58,7
71. Ромодан	57,4
72. Буа	57,4
73. Столбище	57,4
74. Солтан	55,9
75. Салман	55,3
76. Буденный	54.4
77. Константиновка	53,8
78. Морт	51.0
79. Минзәлә	50,0
80. Иске Чишмә	50,0
81. Кама тамагы	50,0
82. Биләр	49,2
83. Карамалы	49,1
84. Әхмәмәт	49,0
85. Кызыл юл	48,9
86. Арча	48,8
87. Казанбаш	48,5
88. Майдан	48,3
89. Макыл	47,2
90. Питрәч	46,8
91. Балык бистәсе	46,0
92. Черемуховский	44,4
93. Тат. Ялтаң	43,9
94. Мамадыш	43,5
95. Иске Писмән	43,3
96. Чишмә	39,4
97. Үзәк	38,2
98. Тат Ходяш	37,5
99. Чиябаш	36,5
100. Кузнечиха	34,9
101. Ключи	34,5
102: Трехозерский	34,0
103. Зур Поляна	31,6
104. Биектау	31,2
105. Әлки	30,4
106: Кошкино	28,3
Барлыгы:	65,0
1943 нче елның 20 нче февраленә.	63,4

ГАЗЕТА УКУЧЫЛАР ИГЪТИБАРЫНА!

«Кызыл Татарстан» газетасының киләсе номеры 5 нче мартта чыга.

Җаваплы редактор И. ҮЗБЕКОВ.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор, редактор урынбасары— АТС 76—29, секретарь, промышленность. транспорт һәм авыл хуҗалыгы бүлеге— АТС 79—29. типография 36—60.

ПФ1068 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФ ИЯСЕ № Заказ 350